

1 апрельдә «Мордовия Республикасында янгын куркынычы чоры» темасына Мордовия Республикасы Матбугат vзәгендә 2025 елнын яз башы, жәйге-козге янгын куркынычсызлыгын профилактикалауга багышланган матбугат конференциясе vтте.

Чарада теманы ачыклап тvбәндәге спикерлар чыгыш ясады: Сергей Викторович Репин, Мордовия Республикасы буенча Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгы Баш идарә житәкчесе (начальник Главного управления МЧС России по Республике Мордовия); Андрей Геннадьевич Наумов, Мордовия Республикасынын Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча Дәvләт комитеты рәисе (Председатель Государственного комитета по делам гражданской обороны и чрезвычайным ситуациям Республики Мордовия); Иван Васильевич Новиков, Мордовия Республикасы Урман, аучылык хужалыгы һәм табигатьтән файдалану министры вазыйфаларын вакытлыча башкаручы (ВРИО министра лесного, охотничьего хозяйства и природопользования Республики Мордовия).

Мордовия Главасы Артём Здунов кушуы буенча республика территориясендә янгынга каршы махсус режим 1 апрельдән 30 сентябрьга кадәр кертелде. Яз башы иртә башланды, коры vлән ягу очраклары ешаю сәбәпле шундый карар кабул ителде.

Спикерлар билгеләп vткәнчә, янгынга каршы барлык чаралар каралган, 470 берәмлек техника әзер, 772 хезмәткәр карамагында 12 янгынга каршы станция эшли, Мордовия Республикасында урманнарда янгынга каршы тору очен оч дәрәжәдән торган комплекслы система кулланыла.

Хормәтле гражданнар, исегезгә тошерәбез, куркынычсызлык мәсьәләләренә игътибарлы караш - кешеләрнен тормышы һәм сәламәтлеге, молкәтнен сакланышы һәм табигый байлыкны саклау очен гарантия! Үзегезне һәм якыннарыгызны саклагыз - янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен vтәгез!

Янгын ялгышларны кичерми. Янгынга каршы режим вакытында учаклар якмагыз. Учак ягучыларны штрафлар да котә.

**Н.ХӘЛИЛ**